СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№6**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Дүртөйле авылында гражданнар-ның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча ха-лык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1.Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Дүртөйле авылында Дүртөйле авылы, Күпер урамы, 18 нче йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 11 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Дүртөйле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 520 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1040 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган ак-чаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлның буй профилен төзәтү; кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту) .

- урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткыч сатып алу)?

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Дүртөйле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм

халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:Татарстан Республикасы, Арча районы, Дүртөйле авылы, Күпер урамы, 18 нче йорт.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков